Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XLIII-9**

Балык Бистәсе штп. 2019 елның 26 июне

Җир кишәрлеген арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен билгеләү турында

Җир кишәрлекләреннән нәтиҗәле файдалану максатларында, Россия Федерациясенең, Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарына туры китереп, Россия Федерациясе Җир кодексының 39.11 маддәсенең 14 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы "Балык Бистәсе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге территориясендә үзидарәлек милкендә булган яисә дәүләт милке чикләнмәгән Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан дәүләт кадастр бәяләве нәтиҗәләре аукцион үткәрү турында карар кабул итү датасына хәтле биш елдан элегрәк расланмаган җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен түбәндәге күләмдә билгеләргә:

-авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яки авыл хуҗалыгы файдалануындагы зоналар составындагы һәм авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган җирләргә караган андый җир кишәрлегенең кадастр бәясенең бер ярым проценты (1,5%);

-шәһәр (авыл) җирлекләрендә урнашкан торак пунктлар җирләренә караган һәм рекреация максатлары өчен файдаланыла торган андый җир кишәрлекләренең кадастр бәясенең бер ярым проценты (1,5%);

-авыл җирлекләрендә урнашкан торак пунктлары җирләренә караган һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклар өчен (ЛПХ – ШЯХ), индивидуаль торак төзелеше өчен файдаланыла торган андый җир кишәрлегенең кадастр бәясенең егерме биш проценты (25%);

-шәһәр җирлекләрендә урнашкан торак пунктлары җирләренә караган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык өчен (ЛПХ – ШЯХ) файдаланыла торган андый җир кишәрлегенең кадастр бәясенең егерме проценты (20%);

- шәһәр җирлекләрендә урнашкан торак пунктлары җирләренә караган һәм индивидуаль торак төзелеше (ИЖС – ИТТ) өчен файдаланыла торган андый җир кишәрлегенең кадастр бәясенең унбиш проценты (15%);

-территорияне комплекслы үзләштерү яки дача хуҗалыгы алып бару өчен "Россия Федерациясендә бәя кую эшчәнлеге турында"Федераль закон нигезендә базар бәяләве (бәясе) нәтиҗәсе буенча тәгаенләнгән беренче аренда түләве (Россия Федерациясе Җир кодексының 39.18 маддәсенең 7 пункты нигезендә аукцион үткәрү очрагыннан гайре).

2. Татарстан Республикасы “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә үзидарәлек милкендә булган яисә дәүләт милке чикләнмәгән Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә урнашкан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелмәгән категория җирләргә караган, шулай ук кадастр бәяләве нәтиҗәләре аукцион үткәрү турында карар кабул итү датасына хәтле биш елдан элегрәк расланган җир кишәрлекләрен арендалау шартнамәсе төзү хокукына аукцион предметының башлангыч бәясен базар бәяләве (бәясе) нәтиҗәләре буенча тәгаенләнгән еллык аренда түләве күләмендә билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы рәисе Вафин Ф.М.ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы И.Р. Таҗетдинов